ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11–12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:
а) унөченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
б) түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче – уналтынчы абзацлар өстәргә:
«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы көчләре һәм чаралары белән ландшафт (табигый) янгыннарын сүндерүне (урман фонды, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендә урман янгыннарын һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарын Россия Федерациясе Урман кодексының 51 статьясындагы 5 өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла торган сүндерүдән тыш) оештыру;
«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте бүлекчәләре көчләре белән янгын сүндерүне (урман янгыннарыннан, федераль янгынга каршы хезмәтнең махсус һәм хәрби бүлекчәләре төзелә торган ябык административ-территориаль берәмлекләрдәге, аеруча мөһим һәм режимлы оешмалардагы янгыннардан, федераль янгынга каршы хезмәтнең

объект бүлекчәләре төзелә торган оешмалардагы янгыннардан тыш, шулай ук кешеләр массакүләм җәлеп ителә торган федераль дәрәҗәдәге чаралар уздырганда) гамәлгә ашыру;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы янаган торак пунктлар исемлеген раслау;»;

в) ундүртенче абзацны унҗиденче абзац дип санарга;

2) 5 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче өлеш өстәргә:

«Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләреннән муниципаль районнар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү керә.»;

б) өченче өлешне дүртенче өлеш дип санарга һәм анда «Җирлекләрнең, шәһәр округларының торак пунктлары чикләрендә» сүзләрен «Җирлекләрнең, муниципаль районнарның, шәһәр округларының» сүзләренә алмаштырырга;

3) 25 статьяның икенче өлешендә «юк итүгә халыкны» сүзләре алдыннан «профилактикалауга һәм» сүзләрен өстәргә, «урман һәм башка янгыннарның» сүзләрен «урман янгыннарының һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарының, шулай ук бүтән янгыннарның» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 05 апрель
№ 12-ТРЗ